| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Нижнеуратьминского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Түбән Уратма авыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|
| 423567, Нижнекамский район,<br>с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1 | 423567, Түбән Кама районы,<br>Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1 |

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

16.05.2022 ел № 9

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 октябрендәге 22нче номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, ТүбәнУратмаавыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Түбән Уратма авыл җирлеге Советының «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук «Түбән Уратма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 30 октябрендәге 22 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында игълан итәргә һәм Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 июнендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Р. Гарифуллин